Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлеге составына керүче Урахча авыл җирлегендә гражданнар җыены

# КАРАРЫ

29 ноябрь 2021 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Уракчы авыл җирлеге составына керүче Урахча авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең Уракчы авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- авыл җирлеге чигендәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту өчен ;

- Уракчы авылы Яр буе урамы юлларын ремонтлау, Совет урамы чокырларын тигезләү , Мельничный Починок авылы Давыдов урамы юлларын ремонтлау , Елгаарьягы урамы чокырларын тигезләү , Наратлы авылы Карбышева урамы юларын ремонтлау өчен;

-трактор өчен өстәмә җиһазлар сатып алу;

- су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү өчен;

- авыл җирлеге чигендәге су белән тәэмин итү җайланмаларын тәртиптә тоту өчен (суэтем башняларына тирәнлек насослары сатып алу өчен);

- авыл җирлеге чикләрендә урамнарны яктырту һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- Уракчы авылында балалар һәм спорт мәйданчыклары урнаштыру.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36Айорт; Мельничный Пүчинкәсе авылы, Киров урамы, 20Б йорты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Гәрәев Ф.М.

Уракчы авыл җирлеге башлыгы: Гәрәев Ф.М